Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района Республики
Татарстан
Совет города Арск
422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

# КАРАР

**« 28 » гыйнвар 2026 ел** **№ 2**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Купербаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2025 елның 20 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Купербаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Купербаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2025 елның 20 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2026 елның 10 февралендә 14 сәг.00 минутта Арча районы, Купербаш авылы, Мичурин урамы, 10 йорт адресы буенча билгеләргә.

2. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Купербаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2025 елның 20 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2026 елның 10 февралендә 14 сәг. 20 минутта Арча районы, Купербаш авылы, Мичурин урамы, 10 йорт адресы буенча билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Купербаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре

турында» 2025 елнын 20 ноябрендәге 4 номерлы карарында гражданнар жыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Купербаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән, 1 төркем инвалидлар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итүдән тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Купербаш авылынын урамнарында юл өслегенең түшәмә катламын төзү)?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Купербаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2025 елның 20 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Арча шәһәре башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урында мәгълүмат стендында (Купербаш авылы, Мичурин урамы, 10 йорт), интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге Башлыгы в.б. Г.Х.Нигмәдҗанова